| СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|
| 422610 г.Лаишево,<br>ул. Первомайская, д.39<br>тел: (8-84378) 2-51-51<br>факс: (8-84378) 2-55-55 | 422610 Лаеш ш.,<br>Беренче май урамы, 39 нчы йорт,<br>тел: (8-84378) 2-51-51<br>факс: (8-84378) 2-55-55 |


**2023елның 31 июле** **78-РС номер**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә, 2023 елның 11 июлендәге ачык тыңлаулар беркетмәсен, 2023 елның 12 июлендәге ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне карап чыгып, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы **карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын (1 нче кушымта) расларга.
2. Лаеш муниципаль районы Советының 2022 елның 31 гыйнварындагы 15-РС номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Егорьево авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен әлеге карар үз көченә кергән вакыттан үз көчен югалткан дип таныргa.
3. Әлеге карарны "Кама ягы" («Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп тору Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.П. Шитовка йөкләнә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы Рәисе** **И.Ф. Зарипов**